

КАРЛ ФЕОДРОВИЧ ФУКС

# КАРЛ ФЕОДОРОВИЧ ФУКС

Карл Феодорович Фукс үткән йөзнең беренче яртысында Казан шәһәренең иң күренекле кешеләреннән берсе була. Фукс урамы белән Фукс бакчасы, Карл Феодоровичның эшлекле тормышы кебек үк матурлык белән тулган шушы бакча гына хәзерге Казан кешеләренә Карл Феодоровичны беркадәр хәтерләтеп тора.

Клиника врачы, анатом, табигатне өйрәнүче, археолог, этнограф, тарихчы, борынгы акчалар белгече, телче, гыйлми сәяхәтче һәм язучы, үз заманының иң укымышлы кешесе булган К. Ф. Фуксның исме — Казан университетының беренче еллары тарихы белән һәм Казан краенда агарту хәрәкәте белән бик нык бәйләнгән. Ул шушында илле ел чамасы сызганып эшләп килде.

Чыгышы ягыннан немец булган Карл Феодорович 1776 нчы елны Рейн елгасы буендагы кечкенә генә Герборн шәһәрендә, Академия профессоры семьясендә туа. Балалык һәм яшьлек вактында Фукс Герборн шәһәренең фәнни тикшеренүләр белән танылган профессорлары арасында яши. Бу мохит белән якыннан бәйләнештә булганлыктан, Карл Феодорович шушы мохитның күп төрле интереслары белән азыкланып үсте. Кече яшьтән үк ул сәламәт һәм зирәк акылы белән таныла һәм фән өлкәсенең талантлы бер вәкиле булып үсә.

17 яшькә чаклы Фукс атасы янында, өйдә тәрбияләнә һәм укый. Борынгы классикларны ныклап өйрәнүгә ул күп кенә вактын бирә. Фукс классик һәм реаль тәрбия системалары белән тәрбияләнә. Ул шушы системалардан һәркайсының иң яхшы якларын ала.

Фукс латин, инглиз һәм француз телләрен бик яхшы белә, итальян телен дә яхшы гына үзләштерә; ә немец теле инде — аның үз ана теле; гарәп һәм борынгы грек телләрен дә бик тиз өйрәнә ул. Шуның өстенә ул Казанга күчкәч рус һәм татар телләрен өйрәнә. Соңыннан ул рус телендә лекцияләр укый, ә дәвалану өчен үзенә килүче күп санлы татарлар белән татарча сөйләшә, хәтта аның „табиб Фукс" дип татарча язылган печате дә була.

Фукс үзенең студентлык елларын немецләрнең борынгы Геттинген университетында зур эшлеклелек белән үткәрә. Анда ул үз эпохасының күренекле галимнәреннән Врисбергның (анатомия), Блюменбахның (табигыят), Рихтерның (практик медицина) лекцияләрен тыңлый. Ул телләрне һәм көнчыгыш әдәбиятын тикшеренүләре белән танылган профессор Эйхгорнның әдәбият тарихы турындагы лекцияләрен тыңлый. Зур галим һәм язучы, физика профессоры Лихтенберг студент фуксның үсешенә һәм карашларына иң зур йогынты ясаучылардан була. 22 яшьлек егет чагында Карл Феодорович Марбург университетында докторлык дәрәҗәсенә диссертация яклый. Бу диссертация 16 нчы йөзнең күренекле табигыят галиме булган һәм канның әйләнеше турында бик күп еллар алдан әйтеп узган Андрей Цезальпинскийнең гыйлми әсәрләрен һәм хезмәтләрен тикшереп язуга багышланган. Кан әйләнеше соңыннан Гарвей тарафыннан ачыла. Үзенең диссертация тезисларыннан берсендә Фукс, төпле һәм киң белемнән башка яхшы врач булырга мөмкин түгел, дигән фикерне әйтә. Гиппократның „врач — аллага ошашлы акыл иясе" дигән сүзләрен ул үзенең диссертациясенә эпиграф итеп ала.

Диссертацияне яклаганнан соң Фукс үзенең ватанында медицина практикасы белән ике ел буена шөгыльләнә, ә 1800 нче елда Петербургга бара. Россиягә аның нинди сәбәпләр белән киткәнлеге билгеле түгел. Ләкин Наполеон һөҗүмнәре астында җәфаланучы Германиядә туган политик хәл Фуксның китәргә уйлавында зур роль уйнаган булса кирәк. Россиядә ул биш ел буена әле полк врачы, әле фәнни тикшеренүче булып эшли. Табигатне, бигрәк тә үсемлекләрне тикшерү уе белән ул көнчыгыш

Россиягә, Уралга сәяхәт итә. 1805 нче елны Россиянең үсемлекләр дөньясын тикшерү турында бай мәгълүмат тапшыра һәм Казан университетына табигать тарихы һәм ботаника профессоры итеп билгеләнә.

Узган йөзнең башында Казан шәһәре культура дөньясыннан читтә калган дип санала. Уңайлы юллар булмавы аның ерак, караңгы һәм надан окраина хәлендә яшәвенә сәбәп була. Ялангач далалар, урманнар, аркан белән сөйрәп йөртелә торган борынгы заман көймәләре йөзгән елгалар, кешеләрне сату гади бер күренеш булып күренгән рәхимсез крепостнойлык хокукы, рустан башка халыкларны кысрыклаучы рус колонизациясе, — К. Ф. Фукс монда әнә шуларны очрата. Соңрак ул: „Монда килеп тора башлаганда мин кыргый диярлек кешеләрне очраттым" ди. Хәтта дворяннар, бигрәк тә дворян хатынкызлары арасында да укый-яза белмәүчеләр еш очрыйлар.

Университетның ачылуын Казан шәһәре салкын каршы ала. Университетның беренче эшлеклеләрен чолгап алган мораль шартлар бик авыр булалар. Уку-укыту өчен кирәкле әйберләр бөтенләй булмый, университет директоры Яковкин үзен диктатор итеп тота, университетка попечитель тарафыннан түбәнге мәктәп режимы кертелә. Фукс Казанда әнә шундый шартларда эшли башлый. 1814 нче елның 5 нче июлендә университет үзенең факультетлары белән, университет уставы буенча сайлап куелган деканнары һәм ректоры белән тулысынча ачыла.

Тиз арада барсы да диярлек немецлардән генә торган профессорлар килә башлый. Немец профессорлары үзләренә 19 кафедраны алалар. Казан чиновниклары консерватизмы җирлегенә күчерелгән бу немец профессорлары колониясенең хәле шактый кысынкы була. Җәмгыять һәм хөкүмәт 1812 нче елгы сугыш уңае белән чит ил кешеләренә шикләнеп карыйлар. Профессорлар Казан чиновникларының тупаслыкларыннан зарланалар. Профессор Сторль чиновникларның үзенә „сукбай итеп, ниндидер, малай итеп" караулары турында нәфрәтләнеп яза. Фукс үзе дә болай ди: „Безнең галимнәр сословиесе ул вакытта бик нык кимсетелә иде. Барсы да безнең белән гадәттән тыш тупас мөгамәлә иттеләр. Казан-

ның элекке коменданты Есипов, минем белән юньләп танышмас борын ук миңа „син“ дип дәшә иде“. Немец профессорларының күбесе шундый мөнәсәбәт өчен яшь университетка салкын, хәтта дошманлык күзе белән карыйлар. Фукс, Браун, Френ һәм башка кайберәүләр кебек фән өлкәсендә дәрт белән эшләүчеләрнең зур булмаган төркеме генә университетка үзенең көчләрен һәм белемнәрен кызганмыйча бирәләр.

Фукс кече яшеннән үк профессорлык эше белән кызыксына. Үзе белән бергә эшләүче башка немецләрдән ул рус телен тиз өйрәнүе белән аерыла. Күп кенә немец профессорлары Казанга ирексез сөрген урны итеп карыйлар. Ләкин Фукс өчен ул сөрген урны булмый һәм, Фукс үзе әйтмешли, ул тиздән аның икенче ватаны булып әверелә. Ул Көнчыгышны ярата, Казан шәһәре аның теләп килгән шәһәре була. Хәтта аның үз йорты өчен урынны шәһәрнең татарлар яши торган өлеше үзәгендә сайлавы да аның Казанда яшәүче татарларны якыннан торып өйрәнергә омтылганлыгын күрсәтә.

Медик булу ягыннан ул, врач — табигатне һәр яктан өйрәнергә тиеш, диючеләрдән берсе була. Аңа Шеллингның табигат турындагы философик идеяләре зур йогынты ясыйлар. Фукснын студентлык елларында табигатне өйрәнүчеләр һәм медиклар бу идеяләр белән мавыгалар. Үсемлекләр һәм бөҗәкләр җыю өчен, ул үзенең ботаника лекцияләре программасына студентлар белән кырга чыгып йөрүләрне кертә. Ул вакытта Казан университетында укыган күренекле рус язучысы С. Т. Аксаков студентлар арасында Фукс шәкертләренең күбәләкләр җыю белән мавыгуларын шатлык белән искә ала. Фукс тарафыннан бирелә торган сәламәт, җанлы юнәлеш озак саклана. Казан университетында табигат белеменең куелышына һәм табигатне өйрәнүчеләрнең яшь, җирле мәктәбен төзүгә ныклы нигез салына. Студентлар аның үзләренә карашында эчке бәйләнеш һәм дуслык булуын сизәләр. Эчке бәйләнеш һәм дуслык булмаганда, профессорның хәтта тирән белемнәре дә үз шәкертләре өчен үлек капитал булып кала. Студентлар аңа карата шундый ук мөнәсәбәттә булалар һәм замандашларыннан берсенең әйтүенчә, аны „бирелеп яраталар“.

Фукс үз кабинеты буенча үткәрелүче экскурсияләрне үзе алып бара һәм теләүчеләрнең барсына да препаратларны үзе күрсәтә. Бу яхшы традиция күп кешеле оешкан экскурсияләргә хезмәт күрсәтү рәвешендә безнең заманда да сакланып килә.

1819 нчы елны Фукска патология, терапия һәм клиника кафедрасы тапшырыла, ә икенче елны аңа анатомия, физиология һәм суд медицинасы буенча лекцияләр уку йөкләнә. Шулай итеп, берникадәр вакытка ул бөтен медицина факультетын диярлек үз кулына ала. Тиз арада Фукс „врачлык бүлегенең“ (ул вакытта медицина факультеты шулай атала иде) деканы итеп, ә аннан соң университетның ректоры итеп сайлана. Шул заман кешесе аның турында болай ди: „Фукс бу хезмәтендә университеттагы галимнәргә яңа тормыш бирде, үзенә шәһәр халкының хөрмәт белән каравын, университет сословиесенең ышанычын һәм мәхәббәтен казанды“.

Ботаникадан дәрес биргәндә файдалану өчен Фукс үз акчасына ботаника бакчасы эшләтә (хәзерге физиология кабинеты, анатомия театры һәм астрономия обсерваториясе артында). Элек чүп үләннәре үскән һәм ташландык хәлгә килгән бу урын рәткә салынгач, университетның беренче директоры профессор Яковин бу бакча турында „урынының коры булуы ягыннан, вакты белән яз көне бөтен шәһәр халкы өчен бульвар булуы мөмкин, чөнки моның өчен бөтен Казанда шуннан яхшы урынны табу кыен“ дип хыяллана.

Карл Феодровичның медицина өлкәсендәге эше аның Казанга килүе белән үк башлана. Ул гимназия больницасының врачы итеп билгеләнә. Ләкин врач булу сыйфатында киң рәвештә танылуы бигрәк тә 1812 нче елда, Казанга французлар һөҗүменнән качып килүче качаклар һәм ополченецлар тулганнан соң була. Пленгә төшкән французлар арасында башланган йогышлы аурулар шәһәрнең кинәт арткан халкы арасында да киң тарала. Башка врачлар белән бер рәттән, Карл Феодорович Фукска халык арасында таралган бу авыруларны бетерү өчен күп кенә эшләргә туры килә.

„Беренче холера“ эпидемиясе таралган 1830 нчы елда Фукс үзен-үзе аямаучы оста врач булуы белән

аеруча зур дан казана. Фукс үзенең „Заметкалар“ында да бу эпидемия турында яза. Кыска булуга карамастан, алар медицина тарихи әдәбиятында кыйммәтле документ булып торалар. Алар авыруның билгеләрен, ул вакыттагы врачлар тарафыннан кулланылган рецептларны һәм санитария чараларын тасвир итәләр һәм көнкүрешне күз алдына бастыралар. Фукс үзенең бу язмасында: „Сентябрьнең беренче көннәрендә, — Бакалтайда берничә бурлак авырып үлде; врачлар бу гаваньне ябуны һәм андагы гостиницаларны бетерүне таләп итә башладылар“ дип яза. Ләкин түрәләр, холера Нижный Новогород ягыннан түгел, бәлки Симбирск ягыннан килә булса кирәк, дигән фикердә булалар, шунлыктан врачларның кисәтүенә игтибар бирмиләр. Шулай да Бакалтайга полиция чиновнигы җибәрәләр. Бу чиновник шунда ук аурый башлап, бик нык көзән җыерып үлсә дә, холерага каршы бернинди дә чаралар күрелми. Ә эпидемия торган саен кинрәк тарала. Бакалтайда күмәч белән сату иткән ниндидер бер кеше, анда ауру йоктырып, төннә яшеренеп Казанга килә дә Вознесенский урамында аяктан егыла һәм больницага озатыла. Холера башлануы турындагы хәбәр тиз арада бөтен шәһәргә тарала. Фукс болай ди: „Бөтен урамнарда коточкыч хәл бара. Таза тормышлы күп кенә кешеләр шәһәрне ташлап киттеләр, уртачарак тормышлылары, һич югында, ай ярымга җитәрлек ашамлык әйберләре хәзерләргә керештеләр. Крестьяннәр китерә торган ашамлык әйберләре шәһәрнең тышында сатылдылар. Сатучылар товарларын, ә сатып алучылар акчаларын җиргә куялар, шулай итеп, берберсенә йогынмый гына алыш-биреш итәләр иде. Тиздән барлык халык килеп йөри торган урыннарны һәм уку йортларын ябарга туры килде, чөнки кешеләр урамнарда аяктан егылалар һәм үләләр иде“. Менә шундый авыр шартларда врач сыйфатында зур энергия белән эшләп, Карл Феодорович үзен халыкка танытты. Ул, үзе әйтмешли, „көн, төн“ эшли. Икенче елны холера эпидемиясе Нижний Новогородда да башлангач, эпидемиягә каршы көрәшер өчен Фуксны анда җибәрәләр.

Казанда Фуксның йорты күп кенә вакыт дәвалау урнына әйләнә, бу йортка күп санда аурулар киләләр.

Фукс үз йортында беренче тапкыр фәнни клиник күзәтүләр ясарга омтыла. Фуксның татарлар арасында зур ышаныч казануы аларның, им-том итүче табибларын ташлап, медицина ярдәменә ешрак килә башлауларында зур роль уйный. Шәһәрнең беренче атаклы врачы булган Фукс барлык кешеләрне дә кабул итә, ә ярлыларны түләүсез дәвалау гына түгел, хәтта еш кына аларга аптекадан даруларны да үз акчасына алдыра. Фуксның кабул итү бүлмәсе иртәдән үк аурулар белән шыгырым тула; аларның кайберләре ерактан киләләр. Татарлар, хәтта татар хатын-кызлары да дәвалану өчен Фукска гына диярлек мөраҗәгать итәләр. Иртә белән юынып-киенеп беткәч тә, ярлы авыруларны кабул итү Фуксның беренче эше була. Кайбер вакытларда бу эш берничә сәгатьләргә тартыла. Фукс үзенә килүче авыруларның барсына да бер төсле карый, барсын да бер төсле каршы ала, залга алып керә, утыруларын сорый һәм һәркемгә „сез" дип дәшә, үз өендәгеләрне дә „син" дип дәшүнең тупаслык икәнлеген аңлата. Гади халыкның аптека даруларына карашын белгәнлектән, ул мөмкин кадәр аларны йорт дарулары белән дәваларга тырыша, моның өчен Фуксның өй аптекасында һәр вакыт төрле дару үләннәре күп була. Крестьяннәрдән берәрсе аңа дәвалаган өчен бүләк тәкдим иткән вакытта, Фукс, ярлы кешене үпкәләтмичә генә, бүләк алудан баш тарта белә иде: „сез миңа яхшылык эшләргә телисез икән, менә миңа шундый үләнне җыеп китерегез" ди һәм үзенә кирәкле дару үләненең үрнәген күрсәтә иде. Шулай итеп, аның өй аптекасының запасы үзенә килүче аурулар китергән дару үләннәре белән яңартылып тора иде. Безнең үсемлекләрнең дару булу ягыннан көче турындагы файдалы мәгълүматларның халык арасында күп кенә таралуы шул юл белән булса кирәк"[1].

Фукс гадәттән тыш күп төрле эшләр алып бара. 1812 нче елны „Казанские Известия" газетасында, беренче кеше буларак, Казанда торучыларның сәламәтлекләре турында аның кыска мәкаләләре басылып чыга башлый. Фуксның шәкертләреннән берсе аның турында болай дип яза: „К. Ф. Фукс, киң практикасы

[1] К. Лаврский һәм П. Пономарев. „К. Ф. Фукс һәм аның заманы".

булган хәлдә, мондагы климатка хас булган авыруларны тирәнтен өйрәнде, сирәк очрый торган үтә күрүчәнлек белән ул, эпидемияләрнең килеп чыгуын, һаваның үзгәрүен алдан белдерә, һаваның үзгәрүе Казан шәһәрендә торучыларның сәламәтлегенә нинди йогынты ясаячагын дөрес билгели иде. Безнең шәһәрнең көнкүрешен аннан да яхшырак белүче булмагандыр". Аның икенче бер биографы болай дип яза: „краебызның тормышында ул игтибарын юнәлдермәгән бер як та юктыр — ул барын да күрә, күзәтә, язып куя, өйрәнә, барлык такмаклар буенча материаллар җыя, башкаларны да шул ук юнәлештә эшләргә дәртләндерә иде".

Карл Феодоровичның медицина әсәрләре арасында: „Урал заводларында тау һәм завод работникларының авырулары турында" дигән китабы аеруча әһәмиятле. Бу әсәрдә автор хезмәт шартларының эшчеләргә йогынтысы турында һәм алар арасында иң күп таралган авырулар турында мәгълүматлар бирә. Бу хезмәтнең темасы Фуксның шәхсе өчен бик характерлы һәм ул вакыттагы эпоха өчен гадәттән тыш нәрсә, Фукс, беренчеләрдән берсе булып, Сергиевски — минерал суларын тикшерә һәм шул турыда яза. Ул анда беренче тапкыр була, ә 1810 нчы елда „ул суларны тикшерү һәм авыруларга ярдәм күрсәтү өчен" рәсми рәвештә бөтен җәйгә Сергиевскигә җибәрелә. Ул вакытта анда торак йортлары да, килүчеләр өчен уңайлыклар да булмый. Килгән кешеләр чатырларда, палаткаларда, көймәле арбаларда һәм балаганнарда яшиләр, алар урнашкан тирәдә 2000 ләп атлар көтүдә йөриләр иде.

Казан краен „зоология, ботаника һәм экономик көнкүреш ягыннан" өйрәнү һәм бу турыда язу — Фуксның иң зур хезмәтләреннән берсе санала. Ул болай дип яза: „Казанга килгәннән соң мин анда бик күп кызыклы нәрсәләр таптым һәм булдыра алган кадәр барсын да язып бардым. Килү белән үк татарлар минем игтибарымны казандылар. Мин алар белән күңел биреп шөгыльләндем һәм аларның дини җолалары, бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре һәм семья тормышлары турында яздым. Берничә еллар эчендә миңа төрле өязләрнең татар авылларында булырга туры килде, ә кайбер вакытларда үзем дә баргалый идем". Фукс татарлар арасында ышаныч белән фай

даланды. Татарларның көнкүрешендәге, өй тормышындагы иң серле яклар, үлекләрне күмүләр, туйлар, мәчетләрдә һәм өйләрдә намаз укулар, хәтта татар хатын-кызлары көнкүрешенә бәйләнешле нәрсәләрнең барсы да Фукс өчен ачык булганнар. Фуксның „Статистика һәм этнография ягыннан Казан татарлары" дигән китабы гадәттән тыш кызыклы. Билгеле, Фуксның кайбер күренешләргә анализ ясауга булган омтылышлары безнең караш буенча искергәннәр, ләкин аның белән безне йөз елдан артык вакыт аерып торуын онытмаска кирәк.

Үз замандашлары булган татарларның көнкүрешен өйрәнү белән шөгыльләнгәндә, Фукс татар халкының тарихы белән дә кызыксына, борынгы хикәяләрне дә язып бара, кулъязмалар җыйный һәм борыңгы көнчыгыш акчаларының гүзәл коллекциясен төзи. Татар һәм шулай ук рус кулъязмаларын һәм елъязмаларын ентекләп өйрәнгәч, 1817 нче елны ул „Казан шәһәренең кыска тарихы" исемле үз хезмәтенең беренче бүлекләрен бастырып чыгара. Карл Феодоровичның бу әсәре — Болгар шәһәре яшәгән заманнардан башлап Казан тарихы турындагы документларның системалы җыентыгы. Аның бу хезмәте университет газетасында басыла башласа да, тиздән туктатыла. Чөнки, Казан университеты тарихчысы Загоскинның язуына караганда, бу китап „цензура характерындагы комачаулыкларга очрады". Бу китапны басып чыгару эше — инородецларның бунтлары турында — XIX нчы йөзнең икенче унъеллыгы ахрындагы цензура карашлары буенча шактый четрекле мәсьәлә турында сөйли башлаган юлларында өзелә, чөнки шуннан соң аның — христианлык урнаштыру, крайны колонияләштерү, аның администрациясе турындагы шулай ук четрекле мәсьәләләр, татар елъязмаларыннан өзекләр, хәтта Пугачев бунты турындагы мәгълүматларны язуга күчәчәге алдан ук күренеп тора иде... Бик ихтимал ки, мөселман халкы үзәгендә чыга торган газетада барлык бу материаллар турында фикер алышу уңышсыз дип табылгандыр. Фукс хезмәтенең калган өлешен басып чыгаруга хакимнәр Veto салганнардыр"[1].

---

[1] „Казан шәһәренең кыскача тарихы" на соңгы сүз, 1905 ел басмасы.

1815 нче елны Казанда булган һәм 70 кварталны, 1500 ләп йортны һәм 19 чиркәүне һәлак иткән коточкыч янгын вактындагы вакыйга аеруча кызыклы. Янгын булыр алдыннан гына, тарих өчен кыйммәтле документлардан: Иван Грозный заманындагы грамоталардан, актлардан һәм башка борынгы кульъязмалардан күчермәләр алу өчен. Фукс губернатордан архивка керергә рөхсәт сораган. Фукс бу турыда болай дип яза: „Бу вакытта губернатор булып надан бер кеше тора иде. Гәрчә французча лыгырдаса да, ул эштән бигрәк карталар һәм хатын-кызлар турында күбрәк уйлаучан гамсез кеше иде. Ул мине бик тупас кабул итте һәм минем үтенечемә әйе дип тә, юк дип тә җавап бирмәде. Шуннан озак та үтмәде, янгын булды; ут—халык килеп йөри торган урыннарга янгынның өченче көнендә генә кабынса да, шул вакыттагы түрәләрнең оятына каршы, халык килеп йөри торган бу урыннар һәм аларда саклаучы бу кыйммәтле материаллар янып юкка чыктылар. Ялкын губерна правлениесен чолгапалгач,мин аңа керергә һәм грамоталарны коткарырга теләгән идем, ләкин янгын бик көчле булганлыктан, мин үз уемнан кайтырга мәҗбүр булдым. Хәтта крепостька керү өчен дә башта урамнардан ялкын аша диярлек үтәргә кирәк иде“.

Бу янгын турында булган язмалар шәһәрнең тәмам җимерелүенең коточкыч картинасын күз алдына китереп бастыралар, хәтта ул вакыттагы кешеләргә шәһәр җансыз булып күренгән. „Янгын никадәр көчле булса, давыл да шул кадәр көчле булды: күтәрелгән тузан бер саженьлек якынлыкта баручы кешене дә күрергә комачаулый иде. Тузан ялкын белән кушылып һәм аның белән сугышып, гүя аны йотып бара һәм сәгать саен көчәя бара иде. Көн төнгә әйләнде һәм йөрергә мөмкинлек калмады. Һәр җирдә каушап калу һәм коточкыч хәл барды, куркынычсыз бер йорт та булмады, ялкын һәр җирдә куркыныч тудырды. Булакның яртысы диярлек гражданнарның әйберләре белән тулган иде, соңыннан ул әйберләр дә янды. Шуның өстенә коточкыч шаушуны, гауганы, йортларның ишелеп төшүен, крепостьтә кабынган дарының шартлавын, чиркәү кыңгы-

рауларының чыңлавын, барабаннар тавышын, җәяүлеләр, атлылар һәм экипажлар белән тулган урамнарны ниһаять, куе кара төтенне, ут кызыллыгын һәм халыкның кычкыруын кушсаң, бу күренешне дошманның дәһшәтле һөҗүменә яки җәһәннәмгә охшатмыйча мөмкин түгел иде[1]. „Тирә-як 7 чакрымга“, ә икенче мәглүматлар буенча 11 чакрымга ут белән чолганып алынган. Воскресенский (хәзерге Чернышевский) урамында 10 йорт, шулар арасында университет кына янмый калган иде.

Волга — Кама краенда яшәгән башка халыклар: чувашлар, мордвалар, арлар, марилар арасында да Фукс этнографик тикшеренүләр алып бара. Ул аларның барсы турында да заметкалар яза, ә картлык елларында хәтта чуваш телен дә өйрәнә башлый. Ул „инородецлар“ белән кызыксынып, аларны өйрәнү белән генә калмый, аларны ярата да. Ул үзенен хатынына: „Дусым, безнең гади, яхшы күңелле һәм басынкы чуваш халкының язмышында минем ничек катнашуымны син күз алдыңа китерә алмассың“.

Карл Феодоровичның йорты бик яхшы көтепханәне, картиналар галлериясен, кыйммәтле һәр төрле коллекцияләрне эченә алган хәзинә урнын тота. Аның көтепханәсендә, сирәк очрый торган күп сандагы китаплардан тыш, гаят әһәмиятле булган борынгы рус, татар, раскольник кульъязмалары җиналган була. Фуксның ботаника, зоология, минералогия, борынгы акчалар буенча коллекцияләре тулылык һәм кыйммәтлелек ягыннан бик сирәк очрый торган коллекцияләр булалар. Үкенечкә каршы, Фукс үлгәннән соң аларның бик аз өлеше генә сакланып кала, барсы да диярлек сатылып бетәләр. Гаят зур фәнни әһәмияте булган, Алтын Орда заманының һәм көнчыгыштагы төрле халыкларның акчаларын эченә алган борынгы акчалар коллекциясе һәм Казан губернасында яшәүче кошлар, бөҗәкләр коллекциясе генә Фукс исән вакытта ук Казан университеты тарафыннан сатып алынган һәм сакланган.

Сәнгать әсәрләрен бәяләүдә Фукс көчле тойгы белән аерыла. Ул сәнгатьне ярата һәм аңлый. Күп еллар буенча Фуксның йорты Казанда акыл тормышы-

[1] К. Лаврский һәм П. Понамарев „К. Ф. Фукс һәм аның заманы.

ның үзәге булып килә. Анда әдәби җыелышлар булып, җирле язучылар үзләренең әсәрләрен укыйлар. Моңа Фуксның хатыны Александра Андреевна Апехтина да булышлык итә. Ул — поэзия[1] белән һәм иренең йогынты ясавы буенча этнографик һәм тарихи тикшеренүләр белән дә шөгыльләнә. Бу әдәби кичәләрнең темалары итеп: Державинның тууына 100 ел тулу уңае белән аның поэзиясе, Гейне иҗады, Пушкин турында истәлекләр, Фуксның һәм аның хатынының этнографик характердагы әдәби әсәрләре һ. б. алыналар. Җыелышта булучылар, мәсәлән, „татар туе" турында хикәя яки татар хатын-кызлары турында кызыклы мәкалә тыңлыйлар.

„Пугачев тарихы" өчен чын тарихи материаллар эзләп Казанга килгәч, А. С. Пушкинның иң элек крайны яхшы белүче К. Ф. Фукса мөраҗәгать итүе бик табигый. Фукс бөтен көнен бөек шагыйрь белән үткәреп, аның эше өчен файдасы тиярлек Казан кешеләре белән аны таныштырды. Казаннан үзенең хатынына язган хатында Пушкин Фукс турында „акыллы һәм галим немец, миңа зур хезмәт күрсәтте, мин аның белән танышуыма шатланам" дип яза. Пушкин соңыннан да Александра Андреевна Фукс белән хатлар аша бәйләныш тота. „Пугачев тарихы" уңае белән Пушкин тарафыннан аңар дүрт хат язылганлыгы билгеле. Хаталарының берсендә аңардан ул: „яхшылыгы һәм ягымлыгы миндә гомерлеккә истәлек булып калачак Карл Феодоровичка иң тирән хөрмәт белдерүне" сорый.

Пушкин белән очрашу турында Фукс үзе болай дип яза: „1833 нче елда Александр Сергеевич Пушкин Оренбург губернасына барышлый бер тәүлеккә Казанда тукталды. Мин бу күренекле шагыйрьне үз йортымда күрү һәм аның белән иң күңелле, онтылмаслык берничә сәгать сөйләшү бәхетенә ирештем. Ул миннән Пугачевның Казанда булуы турында кайбер мәглүматлар алырга теләде. Ләкин бу мәсьәлә белән бер вакытта да шөгыльләнмәгәнлегемнән, мин аңа кирәкле мәглүматларны тулы бирә алмадым, шулай да ул вакытка кадәр белгәннәремне сөйләдем.

[1] Аның анасы — шагыйрь Г. П. Каменевның туганы. Г. П. Каменевны А. С. Пушкин безнең поэзиядә романтизмны башлап җибәрүче дип атады.

Минем шундый аз әһәмиятле хезмәтләрем өчен дә аның чын күңелдән рәхмәт белдерүе мине бу мәсьәлә белән җиддирәк шөгыльләнәчәгем турында аңа сүз бирергә мәҗбүр итте. Үкенечкә каршы, буш вактым аз булганлыктан, мин онтылмаслык Пушкинның теләкләрен тиз генә үти алмадым. Үлем аны Россиядән тартып алды һәм мине аның теләкләрен үтәү белән үземнең аңа бирелгәнлегемне күрсәтү бәхтеннән мәхрум итте. Ләкин ул үлгәннән соң мин, аның теләген үтәп, онтылмаслык туфрагына да хөрмәт күрсәтү өчен, биргән вагдәмдә торырга нык сүз бирдем. Дүрт ел буе мин нык тырышып, барлык маглүматларны, барлык тарихи истәлекләрне, кулъязмаларны һәм шул вакыттагы вакыйгаләрне күргән Казан кешеләренең сөйләгән сүзләрен җыйдым“.

Фукс тарафыннан җыелган материалларның бер өлеше „Казанские Губернские Ведомости“ газетасында басылып чыга.

Фукс Казанга килгән күренекле табигатче Александр Гумбольдтны да үз йортында кабул итә һәм аны Урал белән, аның минераль байлыклары белән таныштыра. Фукс хөкүмәтнең Урал тауларындагы заводларны тикшерү комиссиясендә катнаша һәм, профессор Рыбушкинның язуына караганда: „Урал сырты астында кыйммәтле металларның чиксез күп булуын, аны эшкәртергә эшчеләр җитмәячәген һәм үзенең байлыгы белән аның Американы да узып китүе мөмкин булуын хөрмәтле сенаторга (Комиссия председателенә) беренче кеше буларак ачты. Бу фикерне күренекле Гумбольдт тә элеп алган һәм үзләштергән иде, ләкин бу фикер асылда безнең күренекле профессорыбыз тарафыннан әйтелде“.

Шул заманның күренекле дәүләт эшлеклесе М. М. Сперанский, юлда барышлый Казанда Фукска кереп чыккач, үзенең көндәлек дәфтәрендә болай дип яза: „Профессор Фукс искиткеч кеше. Аның күп төрле белемнәре бар. Татар медальләрен ярата һәм белә. Татар һәм гарәп телләрен белә. Яхшы күңелле һәм әхлаклы кеше. Бик эшлекле. Медицинада аның татарларга йогынтысы зур“.

Ул вакыттагы күренекле күп кешеләр Казаннан үтеп барышлый Фукска киләләр, край турында маглүматлар сорыйлар, аңа мөрәҗәгать итәләр һәм һәр-

вакыт аның турында, яхшы күңелле, тирән белемле, җанлы һәм кунакчыл кеше, дигән фикер белән китәләр.

К. Ф. Фукс 1846 нчы елда, 70 яшендә үлә. Паралич белән сәламәтлеге какшаган булса да, ул соңгы көннәргә кадәр үзенең медицина һәм җәмагәт эшләрен ташламый. „Бу гомуми авыр югалту турындагы хәбәр шәһәрдә яшен тизлеге белән тарала. Меңнәрчә тавышлар „Безнең Фукс үлгән. Безнең Фукс үлгән“ — дигеләр, һәм кайгы уртаклашучылар төркем-төркем булып, бу кайгылы хәлне үз күзләре белән күреп ышаныр өчен, ашыга-ашыга мәрхумнең йортына бардылар“ („Казанские Губернские Ведомости“).

Фуксны соңгы юлга озатырга халык шул кадәр күп җыела ки, хәтта катафалк Грузинский (хәзерге Карл Маркс) урамына җиткәндә процессиянең койрыгы әле Проломный (хәзерге Бауман) урамы буйлап сузыла. „Күмү процессиясен карап торучы кешеләр урамда гына түгел, йортларның түбәләрендә, койма өсләрендә һәм өй түбәләрендә дә күренәләр. Зур гына төркем татарларның бүрекләрен салып барулары аеруча күзгә бәреләә иде“.

Аны лютеран зиаратендә күмәләр һәм К. Ф. Фуксның кабре белән памятнигы хәзердә дә саклана.

Университетның күренекле эшлеклеләреннән берсе булган һәм аңа үзенең бөтен тормышын биргән анатомия профессоры Евгений Филиппович Аристов Карл Феодоровичның кабре өстендә болай дип сөйли:

„Аның үткән юлы — беренче адымнан соңгы минутка чаклы акылның һәм йөрәкнең барлык көчләрен яхшылыкка гына юнәлдергән бик яхшы кеше тормышының картинасы. Карл Феодоровичның истәлеге яктылыгында иң гүзәл нур — аның якын кешегә тирән мәхәббәте. Аның йөрәге кешеләр арасында аерманы белмәде һәм барлык кешеләргә бер тигез, сүнмәс мәхәббәт белән елылык бирә иде. Барлык кешеләргә дә ул туган итеп карады, ә кечеләргә һәм кимсетелгән кешеләргә ул тагын да ныграк кызгану белән карады“.

*Проф. В. Н. Терновский.*